138

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Һөнәр берлекләре турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы гражданнарының гомумтанылган халыкара хокук нормаларында һәм Татарстан Республикасы Конституциясендә күрсәтелгән һөнәр, җәмгыяви-икътисадый һәм хезмәт хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өчен ирекле рәвештә һөнәр берлекләренә (профсоюзларга) берләшүләрен гарантияли, һөнәр берлекләренең җәмгыяви базар хуҗалыгы үсешендәге, гражданнарның тынычлыгын саклаудагы мөһим ролен таный һәм һөнәр берлекләре эшчәнлегенә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

**1 статья.** Һөнәр берлеге

Һөнәр берлеге (профсоюз) - гражданнарның, шул исәптән югары, махсус урта һәм техник һөнәр уку йортларында укучыларның һөнәр, җәмгыяви-икътисадый, хезмәт хокукларын һәм мәнфәгатьләрен чагылдыру, гамәлгә ашыру һәм яклау өчен төзелгән иҗтимагый оешмасы ул.

2 статья. Гражданнарның һөнәр берлекләрен төзү хокукы

Татарстан Республикасы гражданнары ирекле рәвештә һәм үзләре теләп, алдан рөхсәт алмыйча, һөнәр берлекләре төзергә, шулай ук аларга керергә һәм алардан чыгарга хаклы. Граждан берничә һөнәр берлегенең әгъзасы булып торырга мөмкин.

Һөнәр берлекләре, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда* гражданнар тарафыннан төзелергә мөмкин. Һөнәр берлекләре һөнәр, тармак, шулай ук һөнәр-тармак яисә территория үзенчәлекләре нигезендә төзелергә мөмкин. Бер һөнәр (һөнәрләр төркемнәре) кысаларында төзелүче һөнәр берлекләренең саны чикләнми.

Һөнәр берлеге кимендә ун граждан инициативасы буенча төзелә.

Һөнәр берлегендә әгъза булып тору һәм һөнәр берлеге эшчәнлеге белән шөгыльләнү гражданнарның закон тарафыннан гарантияләнгән шәхси, һөнәр, хезмәт, җәмгыяви-икътисадый, сәяси хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә китерми.

Эшләмәүче пенсионерлар һәм шулай ук предприятиедәге эшен югалткан кешеләр һөнәр берлекләрендә әгъзалыкларын саклап калырга, йә булмаса, һөнәр берлекләре уставы нигезендә башка һөнәр берлегенә керергә хаклы.

Барлык һөнәр берлекләре тигез хокукка ия.

---

* Алга таба - предприятиеләр.

3 статья. Һөнәр берлегенең уставы

Һөнәр берлеге, һөнәр берләшмәсе** төзүдә үз теләге белән башлап йөрүчеләр гомуми җыелыш, конференция (корылтай) җыялар, анда устав яисә нигезләмә кабул итәләр. Устав яисә нигезләмәнең һәм гамәлгә куючы башка документларның күчермәләрен исәпкә алу теркәве өчен тиешле дәүләт органнарына кертәләр.

Һөнәр берлегенең уставы яисә нигезләмәсе түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш:

- һөнәр берлегенең исемен, максатларын һәм бурычларын, җәмәгать оешмасы буларак, аның хокукларын һәм җаваплылыгын;

- һөнәр берлегенә әгъза булып керү һәм аннан чыгу шартларын һәм тәртибен;

- һөнәр берлекләре әгъзаларының хокукларын һәм бурычларын;

- һөнәр берлегенең төзелешен, нинди тармакка һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда кайсы территориягә каравын;

- һөнәр берлегенең сайланылучы (җитәкче) органнарының оешу тәртибен, вәкаләтләрен һәм җаваплылыгын, әлеге органнарның вәкаләтләре чорын һәм хокукый зат буларак хокукларын;

- һөнәр берлеге берләшмәләренең республика, территория һәм тармак берләшмәләрен төзү шартларын;

- һөнәр берлеге бюджетының акчаларын, һөнәр берлеге һәм аның оешмаларының башка мөлкәтен булдыру чыганакларын, аларның барлыкка килү һәм аларны куллану тәртибен, һөнәр берлеге ор-

---

** Алга таба - һөнәр берлеге.

ганнарының һөнәр берлеге бюджетының үтәлеше турында хисап тотуын;

- һөнәр берлегенең эшчәнлеген туктатып тору һәм туктату тәртибен һәм нигезләрен.

Уставта һөнәр берлеге эшчәнлегенә кагыла торган башка нигезләмәләр дә каралган булуы мөмкин.

һөнәр берлеге уставы законнарга каршы килмәскә тиеш.

4 статья. һөнәр берлекләренең берләшү хокукы

һөнәр берлекләре, аларның тармак, территория һәм беренчел оешмалары ирекле рәвештә һөнәр берлегенең берләшмәләрен төзергә хаклы.

Әгәр тармак һөнәр берлеге бер үк һөнәр, бер үк тармакта эшләүче һөнәр берлеге әгъзаларының яртысыннан артыгын берләштерсә, ул республика һөнәр берлеге буларак танылырга мөмкин.

Әгәр һөнәр берлекләре берләшмәсе республика тармак һөнәр берлекләренең яртысыннан артыгын берләштерсә, ул республика берләшмәсе буларак таныла ала.

һөнәр берлекләре үзләренең республика тармакара берләшмәләрен төзи алалар һәм республика тармакара органнарын сайлый алалар.

һөнәр берлекләре профсоюзларның республикаара, халыкара берләшмәләренә һәм оешмаларына керергә, алар белән хезмәттәшлек итү хакында шартнамәләр һәм килешүләр төзергә хаклы.

5 статья. Һөнәр берлекләренең бәйсезлеге

Әгәр законнарда башкасы каралмаган булса, һөнәр берлекләре үз эшчәнлекләрен башкарганда дәүләт һәм хуҗалык органнарыннан, эш бирүчеләрдән (аларның берләшмәләреннән), сәяси һәм җәмәгать берләшмәләреннән бәйсез булалар , аларга хисап тотмыйлар һәм алар тарафыннан тикшерелеп тормыйлар.

Дәүләт органнарының һәм урындагы затларның һөнәр берлекләре эшчәнлегенә тыкшынулары, шулай ук һөнәр берлекләренең дәүләт органнарының һәм урындагы затларның эшчәнлекләренә тыкшынулары рөхсәт ителми, моңа законнарда каралган очраклар керми.

6 статья. Һөнәр берлекләре эшчәнлегенең хокукый нигезе

Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм башка законнар һөнәр берлекләре эшчәнлегенең хокукый нигезен тәшкил итәләр.

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендәге һәр предприятиегә кагыла.

Әлеге Законны эчке эшләр һәм дәүләт иминлеге органнарында, башка гаскәри төзелмәләрдә куллану үзенчәлекләре шушы оешмалар турындагы законнар тарафыннан билгеләнә.

Әлеге Законның нигезләмәләре Татарстан Республикасында яшәүче һәм эшләүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыксыз затларга, шулай ук Татарстан Республикасының, командировкага җибәрелеп, читтә яшәүче гражданнарына карата да кулланыла.

Гамәлдәге законнар һөнәр берлекләренең гомумтанылган халыкара хокук нормаларында каралган хокукларын чикли алмыйлар.

һөнәр берлекләре эшчәнлегенең башка законнарда беркетелгән гарантияләренең әлеге Законда булмаулары һөнәр берлекләренең хокукларын чикләү буларак каралырга тиеш түгел.

7 статья. һөнәр берлекләре милке

һөнәр берлекләре законнар нигезендә хокукый зат булалар.

һөнәр берлекләре милек рәвешендә биналар, корылмалар, торак фонды, нәшриятлар, учреждениеләр (дәвалау, ял итү, фәнни, мәгълүмат, укыту-тикшерү, мәдәни, спорт, балалар һәм башка төрдәге) һәм шулай ук башка мөлкәт тота алалар.

һөнәр берлекләре үз милкендәге мал-мөлкәткә, акчага һәм кыйммәтле кәгазьләргә хуҗа булалар, алардан файдаланалар һәм алар белән эш итәләр, дәүләт һәм хуҗалык органнары, предприятиеләр, эш бирүчеләр (аларның берләшмәләре), җәмәгать оешмалары йөкләмәләре өчен җавап бирмиләр, үз чиратында соңгылары да һөнәр берлекләре йөкләмәләре өчен җавап бирмиләр.

һөнәр берлеге бюджетларының чыганаклары, аларны оештыру һәм акчаларын куллану тәртибе һөнәр берлекләренең уставлары (нигезләмәләре) тарафыннан билгеләнә.

һөнәр берлекләре законнарда билгеләнгән тәртиптә үзләренең банкларын, иминлек, хәйрия фондларын һәм башка фондларын, ассоциацияләрен, акционерлык җәмгыятьләрен, уртак предприятиеләрен төзергә, туристлык, нәшерлек, тышкы икътисадый эшчәнлек һәм башка төр финанс, хуҗалык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә хаклы. Бу эшчәнлекләрдән килгән акчалар уставта билгеләнгән вазыйфаларны гамәлгә ашыруга юнәлтелә.

һөнәр берлекләре карамагындагы предприятиеләрнең керем

чыганаклары, алынган акчаларның күләме һәм салымнар түләүне тикшереп тору законда билгеләнгәнчә дәүләт финанс органнары һәм салым инспекцияләре тарафыннан башкарыла.

Һөнәр берлекләре тарафыннан төзелә торган хезмәттәшлек, эшсезләргә ярдәм итүче фондлар, иминлек, пенсия, мәдәни-агарту һәм башка төрдәге җәмгыяви яклау фондлары салымнар түләүдән азат ителә. Предприятиеләр табышыннан салым законнарда билгеләнгән чикләрдә әлеге фондларга кертелгән сумма күләмендә киметеп алына.

Һөнәр берлекләренең мөлкәти хокукларын саклау һәм алар милкенең иминлеге һәм кагылгысызлыгы дәүләт тарафыннан гарантияләнә. Бу милек объектлары тиешле һөнәр берлеге органы ризалыгыннан башка хосусыйлаштырыла алмый.

<u>8 статья.</u> Һөнәр берлекләренең эшчәнлеген туктатып тору
яисә аларны тарату

Һөнәр берлегенең үз инициативасы белән эшчәнлеген туктатып торуы яисә үз-үзен таратуы аның уставында яки нигезләмәсендә каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Һөнәр берлегенең эшчәнлеге Татарстан Республикасы Конституциясенә, законнарга каршы килгән очракларда, һөнәр берлеге прокурор тәкъдиме буенча тиешле суд карары нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә таратылырга яисә аның эшчәнлеге туктатып торылырга мөмкин.

## II бүлек. Һөнәр берлекләренең төп хокуклары

### 9 статья. Һөнәр берлекләренең хезмәт ияләре мәнфәгатьләрен чагылдыру, күмәк сөйләшүләр алып бару, күмәк шартнамәләр һәм килешүләр төзү хокуклары

Һөнәр берлекләре хезмәт ияләренең җәмгыяви яклау һәм хезмәт мөнәсәбәтләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәнфәгатьләрен чагылдыралар, дәүләт идарәсенең тиешле органнары, эш бирүчеләр һәм эш бирүчеләрнең берләшмәләре белән җәмгыяви хезмәттәшлек якларының берсе буларак эш йөртәләр.

Һөнәр берлекләре күмәк сөйләшүләр алып барырга, күмәк шартнамәләр, килешүләр төзергә һәм законнар нигезендә аларның үтәлешен тикшереп торырга хаклы.

Җәмгыяви хезмәттәшлек якларының берсе буларак, һөнәр берлекләре вәкиллеге алардагы әгъзаларның санына тәңгәл рәвештә билгеләнә.

### 10 статья. Һөнәр берлекләренең дәүләт һәм җәмәгать эшләре белән идарә иткәндә катнашулары һәм законнар чыгарганда башлап йөрү хокуклары

Һөнәр берлекләре дәүләт хакимиятенең сайлаулы органнарында үз вәкилләре аша дәүләт эшләренә идарә иткәндә катнашырга хаклы.

Һөнәр берлекләренең Республика советы Татарстан Республикасы Дәүләт Советында хезмәт мөнәсәбәтләре һәм хезмәт ияләрен җәмгыяви яклау өлкәсендә законнар чыгарганда башлап йөрү хоку-

кына ия булалар.

Тиешле һөнәр берлеге органнары хезмәт һәм җәмгыяви-икътисадый мәсьәләләр турында норматив актлар кабул итү, аларны үзгәртү яисә гамәлдән чыгару хакындагы тәкъдимнәрен һәм шулай ук бу мәсьәләләр буенча законда билгеләнгән чорда каралырга тиешле норматив актлар проектларын дәүләт хакимияте органнарына, хуҗалык органнарына, эш бирүчеләргә (аларның берләшмәләренә) кертергә хаклы. Һөнәр берлекләре керткән тәкъдимнәр алар катнашында карала.

Гражданнарның хезмәт һәм җәмгыяви-икътисадый хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив актларны кабул иткәндә дәүләт һәм хуҗалык органнары, эш бирүчеләр (аларның берләшмәләре) тиешле һөнәр берлеге органнарына бу хакта бер атна алданрак хәбәр итәргә тиеш.

<u>11 статья</u>. Һөнәр берлекләренең хезмәт хокукларын яклау хокукы

Һөнәр берлекләре, законнарга нигезләнеп, гражданнарның хезмәткә хокукын яклыйлар, халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт сәясәтен, шушы мәсьәләләр хакындагы Татарстан Республикасының закон актларын һәм дәүләт хакимияте органнарының башка карарларын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда катнашалар; эшкә кабул иткәндә, эштән азат иткәндә, ташламалар ясаганда һәм түләүләр биргәндә хезмәт ияләре өчен билгеләнгән җәмгыяви гарантияләрне яклауны тормышка ашыралар.

Дәүләт идарәсе органнары һәм хуҗалык органнары, эш бирү-

челәр инициативасы буенча предприятиеләрне, тармакларны бетерү яисә үзгәртеп кору, җитештерүне тулысынча яисә өлешчә туктатып тору хезмәткәрләрнең күпләп эшсез калуына китерсә, кимендә өч ай эчендә алдан язма рәвештә тиешле һөнәр берлекләре органнарына хәбәр итү, алар белән сөйләшүләр уздыру һәм эшсез кала торган хезмәткәрләргә карата законнар нигезендә җәмгыяви яклау гамәлләрен үтәү шартларында гына башкарыла ала.

<u>12 статья.</u> Һөнәр берлекләренең хезмәтне, сәламәтлекне һәм тирә-як мохитне саклау өлкәсендәге хокуклары

Һөнәр берлекләре эш бирүчеләр тарафыннан хезмәтне, сәламәтлекне һәм тирә-як мохитне саклау турындагы законнарның үтәлешен җәмәгатьчелек тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыралар.

Һөнәр берлекләре әлеге мәсьәләләр буенча норматив актлар әзерләгәндә һәм аларны килештергәндә катнашырга хаклы, билгеләнгән тәртиптә расланучы нигезләмәләргә таянып эш итүче техник хезмәт инспекциясе һәм ышанычлы табибләр хезмәтләре, комиссияләр һәм башка органнар төзергә хаклы.

Техник хезмәт инспекторлары, ышанычлы табибләр тиешле предприятиеләргә тоткарлыксыз кереп йөрергә, хезмәтне һәм тирә-як мохитне саклау нормаларының үтәлешен тикшереп торырга; ачыкланган кимчелекләрне бетерү хакында мәҗбүри күрсәтмәләрне предприятие хакимиятләре һәм эш бирүчеләр карамагына тапшырырга; хезмәт шартлары һәм хезмәт иминлеге буенча бәйсез экспертиза үткәрергә; әгәр алга таба эш итүдән хезмәткәрләрнең сәламәтлегенә яисә тормышына куркыныч яный, эш коралларының,

участокларның, цехларның, җитештерүнең эшен туктату турында таләпләр куярга; җитештерүдәге бәхетсезлек очракларын һәм кәсби авыруларны тикшергәндә катнашырга; бәйсез экспертлар сыйфатында яңа һәм үзгәртеп төзелгән җитештерү объектларын һәм җитештерү чараларын сынау һәм кабул итү комиссиясе эшендә катнашырга; хезмәтне, сәламәтлекне һәм тирә-як мохитне саклау турында хезмәт бәхәсләрен караганда катнашырга; әлеге мәсьәлә турында дәүләт идарәсенең тиешле органнарыннан һәм эш бирүчеләрдән мәгълүмат алырга; хезмәтне саклау һәм җитештерүдә бәхетсезлек очракларын яшереп калу буенча норматив таләпләрне бозган урындагы затларны җаваплылыкка тарту турында тиешле органнарга мөрәҗәгать итәргә хаклы.

<u>13 статья.</u> Һөнәр берлекләренең җәмгыяви иминлек һәм җәмгыяви тәэминат өлкәсендәге хокуклары

Тиешле законнар нигезендә һөнәр берлекләре һәм аларның вәкилләре Җәмгыяви иминлек буенча дәүләт фондына, шулай ук үз карамагындагы шифаханәләргә, профилакторийларга, ял йортларына, туристлык һәм спорт корылмаларына идарә итүдә катнашалар; җәмгыяви тәэминат, медицина иминлеге һәм сәламәтлек саклау органнарында гражданнарның хокукларын законнарда билгеләнгән чикләрдә яклыйлар; табибләр тарафыннан хезмәтне экспертлау комиссияләре эшендә катнашалар.

Һөнәр берлекләре эш бирүчеләрнең имгәнү, һөнәргә бәйле авыру алу яисә башка сәбәпләр аркасында эш вакытында хезмәткәрләрнең сәламәтлегенә килгән зыян өчен түләү турындагы норматив актларны үтәвен тикшереп торалар; дәүләт органнарында

һәм башка урыннарда зыян күрүчеләрнең мәнфәгатьләрен якларга хаклылар.

14 статья. Хезмәт һәм һөнәр берлекләре турындагы, торак-көнкүреш хезмәте күрсәтү турындагы законнарның үтәлешен һөнәр берлекләренең тикшереп тору хокуклары

Һөнәр берлекләре хуҗалык органнарының, предприятиеләр хакимиятләренең һәм эш бирүчеләрнең хезмәт, һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләргә торак-көнкүреш хезмәте күрсәтү турындагы законнарның үтәлешен җәмәгать тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыралар.

Һөнәр берлекләре хезмәт турындагы законнарны, күмәк шартнамәләрне, хезмәткәрләрнең хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы башка килешүләрне төзү һәм гамәлгә ашыру шартларын бозу белән бәйле шәхси һәм күмәк хезмәт бәхәсләрен (каршылыкларны) карап тикшерүдә катнашалар.

Шушы максатларда һөнәр берлекләре хезмәт буенча хокук инспекциясе, хокукый белешмә һәм билгеләнгән тәртиптә расланган нигезләмәләр буенча эш итүче башка органнар төзи алалар. Һөнәр берлекләренең хезмәт буенча хокук инспекциясе хезмәт һәм һөнәр берлекләре турындагы, торак-көнкүреш хезмәте күрсәтү турындагы законнарның үтәлеше буенча тикшерүләр үткәрергә; эш бирүчеләргә һәм хуҗалык органнарына язма күрсәтмәләр бирергә, закон бозуның күрсәтелгән очракларын бетерү хакында дәүләт органнарына тәкъдимнәр кертергә һәм хезмәт турындагы законнарны бозуда гаепләнгән урындагы затларны билгеләнгән тәртиптә җа-

ваплылыкка тартырга хаклы.

Эш бирүчеләр һәм хуҗалык органнары - хезмәт һәм һөнәр берлекләре турында, торак көнкүреш хезмәте күрсәтү турындагы законнарны үтәүдәге кимчелекләрне бетерү хакында һөнәр берлекләре биргән язма күрсәтмәләрне, ә дәүләт органнары тәкъдимнәрне карап тикшерергә һәм аның нәтиҗәләре турында тиешле һөнәр берлеге органына бер ай вакыт эчендә хәбәр итәргә тиеш.

Үз әгъзаларының һәм башка хезмәткәрләрнең хезмәткә хокукын, җәмгыяви-икътисадый хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклап, алар үтенече буенча, шулай ук үз теләкләре белән һөнәр берлекләре судка мөрәҗәгать итәргә хаклы.

15 статья. Һөнәр берлекләренең хезмәт шартлары өлкәсендәге һәм хезмәт өчен түләү өлкәсендәге хокуклары

Хезмәткә ялланган хезмәткәрләрнең эш шартлары һәм хезмәт өчен түләү һөнәр берлекләре катнашында билгеләнә һәм, әлеге Законның 6 статьясындагы өченче өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле законнар нигезендә җайга салына.

16 статья. Һөнәр берлекләренең мәгълүматлар алу хокуклары

Һөнәр берлекләре билгеләнгән статистик хисап чикләрендә хезмәт һәм җәмгыяви-икътисадый үсеш мәсьәләләре белән бәйле мәгълүматларны эш бирүчеләрдән, шулай ук дәүләт идарәсе органнары һәм хуҗалык органнарыннан бушлай алырга хаклы.

Мәгълүматларны тиешле вакытта бирмәгән очракта һәм шулай ук ул тулы булмаган яисә бозып күрсәтелгән очракта, урындагы

затлар һәм эш бирүчеләр законда күрсәтелгәнчә җаваплы булалар.

Һөнәр берлекләре гамәлдәге законнар буенча массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдаланырга, аларда үз эшчәнлекләрен яктыртырга; массакүләм мәгълүмат чараларының гамәлгә куючысы булырга һәм социологик тикшеренүләр үткәрергә хаклы.

17 статья. Һөнәр берлекләренең күмәк гамәлләр үткәрү, эш ташлаулар оештыру һәм уздыру хокуклары

Һөнәр берлекләре законнарда билгеләнгән тәртиптә җыелышлар, митинглар, урам хәрәкәтләре, пикетлар, демонстрацияләр, башка төрдәге күмәк һәм массакүләм гамәлләр оештырырга һәм үткәрергә, шулай ук эш ташлаулар оештырырга һәм уздырырга хаклы.

Ш бүлек. Һөнәр берлекләренең хокук гарантияләре

18 статья. Дәүләтнең һәм предприятиеләрнең һөнәр берлекләренә карата бурычлары

Һөнәр берлекләренә үз уставларында каралган бурычларын гамәлгә ашыруда дәүләт һәм предприятиеләр ярдәм итәләр.

19 статья. Һөнәр берлекләренең сайланылучы хезмәткәрләренең хезмәт хокуклары һәм аларга ташламалар.

Предприятиедә һөнәр берлегенең җитәкче органнарына сайлап кую сәбәпле төп эшеннән азат ителгән һөнәр берлеге хезмәткәрләре барлык җәмгыяви ташламалардан һәм хокуклардан үзләрен

152



сайлап куйган хезмәт коллективы әгъзалары белән бертигез файдаланалар. Аларга законда билгеләнгәннәрдән тыш, күмәк шартнамәдә һәм килешүдә каралган башка ташламалар да бирелергә мөмкин.

Предприятиенең һөнәр берлеге органы составына сайланган һөнәр берлеге хезмәткәрен ул һөнәр берлеге вазыйфаларын башкарырга тиешле бүлекчәгә карамаган башка эш урынына күчерү үзе әгъза булып торган һөнәр берлеге органы ризалыгы белән генә мөмкин.

Һөнәр берлеге органнарына сайланып куелу сәбәпле, җитештерү эшеннән азат ителгән хезмәткәрләргә, аларның сайлануга кагылышлы вәкаләтләре беткәч тә, элеккеге эшләре (биләгән урыннары) бирелә, бу мөмкин булмаган тәкъдирдә - шул ук яисә башка предприятиедә шуңа тиңдәш эш урыны бирелә. Тиешле эш урыны бирү мөмкин булмаган тәкъдирдә - хакимият һәм эш бирүче, ә предприятие бетерелгән очракта тиешле һөнәр берлеге әлеге хезмәткәргә яңа эшкә урнашканда алты айдан да артык булмаган вакыт дәвамында, ә укыган яисә яңа һөнәр үзләштергән очракта бер елга кадәр уртача хезмәт хакын түләп килә һәм шушы дәвердә аның өзлексез эш стажы саклана.

Һөнәр берлекләрендә сайланылучы вәкаләтләрне башкару чоры гомуми, өзлексез һәм махсус эш стажына кертеп исәпләнелә.

## 20 статья. Һөнәр берлегенең сайланылучы хезмәткәрләренә дисциплинар җәза бирелгәндә гарантияләр

Җитештерү эшеннән азат ителмичә генә һөнәр берлеге органнарына сайланган хезмәткәрләр, үзләре әгъза булып торган һөнәр

берлеге органының ризалыгы булмый торып, дисциплинар җәзага тартыла алмыйлар, предприятие бүлекчәләреннән сайланган һөнәр берлеге органнары җитәкчеләре - предприятиенең тиешле сайланучы һөнәр берлеге органы ризалыгыннан, ә предприятиедәге сайланучы һөнәр берлеге органнары җитәкчеләре, һөнәр берлеге оештыручылары тиешле һөнәр берлеге берләшмәсе органы ризалыгыннан башка дисциплинар җәзага тартыла алмыйлар. Бу уңайдан килеп чыккан бәхәсләр законнарда каралган тәртиптә хәл ителәләр.

21 статья. Һөнәр берлегенең сайланылучы хезмәткәрләрен эштән азат иткәндә гарантияләр

Җитештерү эшеннән азат ителмичә генә һөнәр берлеге органнарына сайланган хезмәткәрләрне предприятие хакимияте һәм эш бирүче теләге буенча эштән азат итү, гомуми тәртиптә үтәүдән тыш, бары тик үзләре әгъза булып торган тиешле һөнәр берлеге органының алдан бирелгән ризалыгы буенча гына, ә предприятиедәге һөнәр берлеге органнары рәисләрен һәм әгъзаларын тиешле һөнәр берлекләре берләшмәсенең алдан бирелгән ризалыгы буенча гына рөхсәт ителә.

Һөнәр берлеге органнарына сайланган затларны - сайланылучы вәкаләтләре тәмамланганнан соң ике ел дәвамында, ә һөнәр берлеге органнары рәисләрен өч ел дәвамында предприятие хакимияте һәм эш бирүчеләр теләге буенча эштән азат итү рөхсәт ителми, моңа предприятиенең тулысынча ябылуы, хезмәткәрнең озак вакытка сузылган авыруы, йә булмаса закон буенча эштән азат ителерлек гаепле гамәлләр башкару очраклары керми. Әлеге очракларда эштән азат итү шушы статьяның беренче өлешендә ка-

ралган тәртиптә башкарыла.

22 статья. Һөнәр берлеге эшчәнлеге өчен түләүле вакыт

Һөнәр берлеге вазыйфаларын башкару өчен, җитештерү эшеннән азат ителмәгән һөнәр берлеге органнары әгъзаларына бу вазыйфалар хезмәттән буш вакытта башкарыла алмаганда, шулай ук һөнәр берлеге буенча укулар чорына, делегат буларак һөнәр берлегенең съездларында, конференцияләрендә, президиумнарында, пленумнарында һәм комиссияләре эшендә катнашу өчен күмәк шартнамәдә һәм килешүдә каралган тәртиптә, уртача хезмәт хакын саклап, кирәгенчә түләүле вакыт бирелә.

Түләүле вакыттан тыш, өстәмә рәвештә түләүсез вакыт та бирелергә мөмкин.

23 статья. Тиешле һөнәр берлеге органы эшчәнлеге өчен эш бирүчеләрнең шартлар тудыру бурычлары

Предприятие хакимияте, эш бирүче яисә аның вәкаләтендәге орган тиешле һөнәр берлеге органнарына үзенең уставта каралган эшчәнлеген башкару өчен җиһазландырылган бинаны бушлай файдалануга тапшыра. Транспорт чаралары, оештыру һәм башка төр техника бирү шартлары күмәк шартнамәдә яисә килешүдә карала.

Эш бирүче яисә шул вәкаләтләргә ия булган орган предприятие нисбәтендәге йә арендага алынган биналарны, корылмаларны һәм башка объектларны, шулай ук шифаханәләрне һәм профилакторийларны, мәдәният йортларын, спорт һәм мәдәният сарайларын, ял итү базаларын, балалар һәм яшүсмерләр өчен спорт мәктәплә-

рен, сәламәтләндерү җәйләүләрен, хезмәткәрләрнең һәм аларның гаиләләренең сәламәтлеген ныгыту, ялын оештыру, алар өчен физик тәрбия, сәламәтләндерү һәм массакүләм-мәдәни гамәлләр оештыру өчен кирәкле башка объектларны тиешле һөнәр берлеге органнарына бушлай файдалануга тапшыра. Күрсәтелгән объектларны хуҗалык ягыннан тоту һәм төзекләндерү предприятие чыгымнары хисабына башкарыла. Һөнәр берлекләре үзләренең акчалары һәм башка матди чаралары белән әлеге объектларны тотуда һәм җиһазландыруда катнашалар, шулай ук әлеге җәмгыяви-мәдәни көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларында эшләү өчен кадрлар сайлауда да катнашалар.

Предприятиеләр һөнәр берлеге органнарына күмәк шартнамәләрдә һәм килешүләрдә каралган максатлар өчен һәм билгеләнгән күләмнәрдә акча күчерәләр.

Предприятие тарафыннан матди һәм финанс чаралары тапшырылган һөнәр берлеге органы аларны кулланган өчен законнар, күмәк шартнамә һәм килешү нигезендә җаваплылыкка ия, һөнәр берлегенә, предприятиенең хезмәт коллективына һәм эш бирүчегә тиешле хисапларны тапшыра.

<u>24 статья.</u> Һөнәр берлекләренең эшчәнлегенә каршылык күрсәткән өчен җаваплылык

Дәүләт һәм хуҗалык органнары һәм шулай ук эш бирүчеләр (аларның берләшмәләре) һәм башка урындагы затлар әлеге Закон нигезләмәләрен бозган очракта, һөнәр берлекләре гаепле затларны җаваплылыкка тарттыру өчен судка мөрәҗәгать итәргә хаклы.

156



25 статья. Һөнәр берлекләренең җаваплылыгы

Законсыз гамәлләре белән дәүләткә, хокукый яисә физик затларга зыян китергән һөнәр берлеге китерелгән зыянны законнарда билгеләнгән тәртиптә капларга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 18 гыйнваре
N2303-XII